| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2024 Кошман ав. № 82

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль милкеннән федераль милеккә тапшырыла торган мөлкәт күчемсез милек исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты милкенә яисә муниципаль милеккә федераль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкеннән федераль милеккә яисә муниципаль милеккә тапшыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге турында» 2006 елның 13 июнендәге 374 номерлы карары, муниципаль милектән Россия Федерациясе субъекты милкенә яисә муниципаль милеккә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Уставы карарына таянып, «Автодор» дәүләт компаниясе мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең муниципаль милкеннән «Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлек тәэмин итү өчен җирләр, оборона җирләре, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр» категориясендәге 16:21:150402:369, 16:21:150401:272 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Кошман авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «Восток» М-12 федераль юлының бүленгән полосасын төзи торган җир кишәрлекләрен федераль милеккә түләүсез тапшырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасында һәм Ульяновский өлкәсендә дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча Федераль агентлыкның төбәкара территориаль идарәсенә җибәрергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы<br>Кайбыч муниципаль районы<br>Кошман авыл җирлеге Башлыгы — Л.Р. Сафина